ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

21 октябрь **2024 ел** **№** 765

**2025 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында**

1. 2025 елга түбәндәгеләрне расларга:

1) 2025 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын 1 нче кушымта нигезендә;

2) гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган гомуми белем бирү оешмаларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларына туры китереп финансларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» 10 2024 ел, № 765
карарына 1 нче кушымта

2025 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сум | автотранспорт чарасының бер километрына ставка, сум |
| КАВЗ | 1 128 838,81 | 24,40 |
| ПАЗ | 1 129 096,31 | 24,56 |
| «Газель» ГАЗ | 1 107 926,16 | 15,73 |
| УАЗ | 1 107 472,96 | 14,08 |
| FIAT | 1 110 820,46 | 11,88 |
| Peugeot Boxer | 1 115 970,46 | 11,47 |
| Ford Transit | 1 116 227,96 | 16,08 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 1 131 053,31 | 21,60 |

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«__» _______ 2024 ел, № ____
карарына 2 нче кушымта

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә (алга таба-Нигезләмә) гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба - муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы йөреше нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан ел саен раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда, автотранспорт чараларының факттагы йөреше турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында фактта йөреше буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m, модельле автотранспорт чараларының факттагы йөреше;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән бер километрга йөртүне оештыру бәясенең нормасы, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртү бәясе бер автотранспорт чарасына норматив ставкасы, сум;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар саны.